**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2020 елның 8 сентябреннән № 128

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 19 сентябреннән 101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 4 июненнән 6 номерлы Турай авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең 2020 елның 4 сентябрендәге 1 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2013 елның 4 июненнән 5 нчы номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Көчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Турай авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Турай авыл җирлеге
Советы Рәисе А.М. Рәхимова